# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Җиңү торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**31 октябрь 2024 ел.** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Җиңү торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Загорье торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш 600 сум күләмендә үзара салымны кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җиңү торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

2) Җиңү торак пунктында Үзәк ур., 11 һәм 13 йортларда күпфатирлы торак йортларның су агызу системаларын төзү һәм ремонтлау;

3) Җиңү торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

4) Заречье торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Вахит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru., Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Азнакай муниципаль районының
халык җыенында рәислек итүче,
Вахит авыл җирлегенең Башлыгы Г.И. Әскәрова